Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы
«Россия Федерациясе Герое А.Н.Епанешников исемендәге
3нче урта гомуми белем мәктәбе»
гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе



Тема:
Күренекле татар драматургы, прозаик Туфан Миңнуллин әсәрләрендә шәхес язмышы һәм җәмгыять.

Максат: Туфан Миңнуллинның тормыш юлы, иҗаты белән танышу, аның турындагы язмаларны эзләү, татар әдәбияты тарихындагы  эшчәнлеген ачыклау.

Бурычлар:

- 1. Туфан Миңнуллинның тормыш юлын ачыклау.
- 2. Әдәби иҗатына күзәтү ясау.
- 3. Кешенең кеше буларак аякка басуы, рухи ныгуы, ягъни шәхеснең формалашуы проблемасын ачыклауга  керткән өлешен бәяләү.

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,

Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам;

Каләм кулда була торып, яшь, шагыйрьгә,

Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам.

*Г. Тукай*



# Тормыш юлы

Берсеннән- берсе кызыклы пьесалар иҗат итеп, бүгенге татар сәхнәсен “тотып торган” драматургларның берсе- Туфан Миңнуллин.

1935нче елның 25нче августында Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында Габдулла Миңнуллин гаиләсендә бер малай дөньяга килә. Габдулла агай- әдәбиятка гашыйк кеше, шул еллардагы популяр шагыйрьләрнең берсе булган Хәсән Туфанның псевдонимын малаена исем итеп куя.

Туфан, урта мәктәпне тәмамлагач, беркадәр вакыт төрле эшләрдә эшли. Ләкин аны тормыш сукмагы әдәбият-сәнгать дөньясына борыла. Мәскәүдә М.С. Щепкин театр училищесында укый, Минзәлә театрында, бераздан Г.Камал театрында артист була, Казан телестудиясендә, “Чаян” журналында эшли. Аннары бөтенләе белән иҗат эшенә күчә.

Туфан Миңнуллин – сатирик повесть, шаян хикәяләр, шигъри парчалар һәм эпиграммалар авторы.

# Шулар арасында:

**“Нигез ташлары”**



“Диләфрүзгә дүрт кияү”



Әлдермештән Әлмәндәр



# Ләкин аның таланты тулы булып ачылган өлкә – драматургия.

- Кешенең кеше буларак аякка басуы, рухи ныгуы, ягъни шәхеснең формалашуы прблемасы Т. Миңнуллин иҗатында киң урын ала. Бу темага “Миләүшәнең туган көне”, “Күрше кызы”, “Уйланыр чак”, “Дуслар җыелган җирдә”, “Китәр юлың еракмы?” кебек пьесалары карый. Шәхес һәм аның язмышының формалашуы авторның беренче әсәреннән алып соңгы иҗатына кадәр игътибар үзәгендә тора.



Бу яктан «Миләүшәнең туган көне» һәм «Дуслар җыелган җирдә» исемле драмалар аеруча характерлы. Персонажларның нигездә уртак булуы белән дә , куелган проблемалары ягыннан да алар бер-берсенең табигый дәвамы.









- Бу әсәрләрдә үзәккә кешенең тормышта үз урынын ничек сайлавы, җәмгыять өчен ничек файдалы булу мәсьәләләре куелган. Алар “Миләүшәнең туган көне” драмасында кичәге студент дуслар, бүген мөстәкыйль тормышта беренче адымнарын атлаучы иҗат яшьләре өчен бик җитди һәм катлаулы төс ала. Яшәүнең олы идеалына тугрылык саклау юлында яшь шагыйрь Рәфис,яшь композитор Фәһим, яшь рәссам Нурислам элекке дуслары рәссам Шәһит белән бәрелешкә керәләр, яшь җырчы Миләүшәне аның йогынтысыннан тартып алалар.

“Дуслар җыелган җирдә” драмасында , инде тормыш юлларының уртасына җитеп килгәндә, шул ук геройлар югарыда әйтелгән мөһим мәсьәләләрнең әле дә хәл ителеп бетмәгәнен, үзләре өчен һаман да актуаль икәнен күреп беркадәр аптырашта калалар. Алай гына да түгел, үз тормышыңны мәгънәле итеп, халыкка файдалы итеп кору җиңел эш түгел икәнен аңлыйлар.





Дуслык кебек изге хисне Рәфис һәм Фәһим, Нурислам һәм Гайнуллалар бер-берсенә кунакка йөреп, үзара макташу дип кенә исәпли башлаганнар.
Трилогиянең совет чорында язылган ике кисәгендә драматург җәмгыть һәм кеше мөнәсәбәтен шул чор идеологиясе күзлегеннән торып, ягъни кешенең җәмгыятькә ни дәрәҗәдә файдалы булуы, җәмгыять һәм коллектив һичшиксез җаваплылыгы ноктасыннан торып хәл итә.



# Нәтиҗә:

Драматург Туфан ага Миңнуллин тормышыбызның бик күп өлкәләрен бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп бастыра. Шуңа күрә аның геройлары күңелдә тирән уелып кала. Т. Миңнуллинның барлык әсәрләре өчен уртак сыйфат – кешеләргә карата олы хөрмәт һәм мәхәббәт. Гомумән алганда, аның әсәрләре тормышның нәкъ үзе кебек якты һәм күтәренке нокта. Нәкъ менә чынбарлыктагыча, аларда җитдилек һәм күңеллелек, җиңел рух һәм мәгънә тирәнлеге аралашып, үзара тыгыз үрелеп килә. Бу яктан аның әсәрләрен башка драматурглар пьесалары белән буташтырып булмый.

Туфан Миңнуллин – татар әдәбиятында әйдәп баручы драматург. Ул үзенең тамашачысын тапты, «Туфан театры» дигән гыйбарә барлыкка килде.

Туфан Миңнуллин, башка бөтен драматурглардан үзгә буларак, татар халкының күңелен тирәнтен өйрәнергә омтылды.

Әдипнең иҗат мирасы татар халкын рухи-әхлакый яктан тәрбияли.

*Презентацияне төзүче:*

*Зиятдинова Әлфия Илдар кызы*

*Алабуга шәһәре,*

*3 нче урта мәктәбенең*
*9 «К»*
*сыйныфы укучысы*

*2014 ел.*

***ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН***

***РӘХМӘТ!***